

Еллар узган саен авылларыбыз матурая, күз алда үзгәрә.
Ләмберә турында да шундый сүзләр әйтергә момкин. Без күптән түгел Урманлы урамы турында язган идек, әле урамында матурлык тудыручы һәм туган ягында яшәргә тагы да әйбәт булсын дип тырышучыларны күрәбез. Коз коне булуга карамастан, гөлләре-чәчәкләре тирә-якны ямьләндерә. Бар жирдә тәртип урнашкан. Мәсәлән, Октябрь урамы буйлап үткәндә, ирексездән машина тәрәзәсен ачып матурлыкны хозурлыйсын. Тиз иттереп үтеп булмый булдырылган матурлык тирәсеннән. Рәсемдәге Ильдар Хәйдәр улы Васькиннын ое. Чынлап бәхет кошы кунган йортына!

Коймадан күренеп торган агачларга, тирә-якка ямьлелек беркәп, ап-ак челән-аистлар килеп утырган, әйтерсен әле генә очып кунганнар. Бакчадан тагы башка хайваннар сүрәтләре күренә; могжизага тин матурлык. Гөлләр белән бергә бер композицияне ой хужалары үзләре булдырган.
Агымдагы елнын жәй айларында (гадәткә кергәнчә ярыш һәр ел үткәрелә) Рузаевка шәһәрендә ой алдылары, оешмаларнын тирә-ягын архитектура ягыннан матур һәм яшәү очен унайлы итү конкурсы үтте. Бу конкурска ташландык материалдан үз куллары белән эшләп ой алларына, мәгариф оешмалары тирәләренә ямь остәгәннәрне дә билгеләделәр. Бу ярыш халыкка



яшәү очен матур шартлар тудыра. Дәлил иттереп рәсемдә күрсәтелгән Ленин урамы алтмышынчы йортны алырга була.
Иске Темникта да матур яшәргә теләүчеләр күп. Үзәк урамнын чиста йортлары чәчәккә күмелгән. Район халкына үрнәк буларак, йорт-жир тирәләрен бигърәк матур тоталар!

Ижади якын килеп матурлык тудыручы томән халкы кvп торле әкият сыннарын vз куллары белән ясап бакчаларын бизәгәннәр. Чәчәккә кvмелеп утыручы ишек алдылары кvнелләрне кvтәреп жибәрә.
Нәкъ Иске Шәһәрдә 400гә якын кеше яши, аларнын 175 - пенсионерлар, 178 - эшче халык һәм 51 - яшьләр. Тирә-якны чиста һәм ямьле итv vрнәген дачачы Саровчылар кvрсәтә. Нәкъ алар vзенен экзотик vсемлекләре белән дан казанганнар. Авыл нинди чыгымнарга яши дигәч, Искешәһәр авылы администрациясе житәкчесе М. Н. Долбилин: «Администрация башкара торган эшләргә бvлеп бирелә торган vз доходларыбыз бик кечкенә - земельный һәм имущественный налоглар, НДФЛ һәм район бюджетыннан бирелгән дотацияләр. Шул кечкенә акчага булса да урамнарны тоне буе 31 урам фонаре яктырта, vткән ел 500 метр юл Борисовка һәм башка урамнарга салдык. Бар эштә инвестор Ю.П.Малахаевыбыз ярдәм итә. Анын сарыклар фермасы



бар. Югарыда санап киткән эшләрне башкарырга һәм чvп чыгартырга булышты һәм халыкка эш урыннары булдырды.
Бvген социаль кирәкләргә катастрофически финанслау житми. Шуна туристик юнәлеш остендә тырышып эшлибез. Тарихи яктан Темник жире бик тә истәлекле.
Старогород жире биредә туып vскәннәрне тарта, - ижади һәм хужалык эшләрен яратучыларны, авылларын vстерегә, матур итәргә теләvче кешеләрне. Зур ометләр рәссам һәм язучы якташыбыз  Е.М.Тенишевага баглыйбыз. Кабатланмас шедеврларын нәкъ туган жирендә тудыра! Анын йорты тирәсеннән тыныч кына vтеп китеп булмый; һәрвакыт туктап матурлыкны хозурлыйсын. Ул ачык кvк йозе астында vз куллары һәм фантазиясе белән әкият персонажлары музее булдырган. Тагы Россиядә һәм чит илләрдә билгеле булган рәсемнәрен туган Иске Шәһәрендәге кvргәзмәдә карап булачак.

Мордовия Республикабыз Главасы В. Д. Волков яна мәдәният һәм вакытны кvнелле vткәрv Үзәге булдыруда ярдәм итәргә ышандырды. Кvптән тvгел яшь белгеч Үзәгебезне житәкли; башлады шулай булгач, кая яшь-шунда омет, шунда vсеш, дибез. Бу - актуаль».
Бәхет кошлары сезнен дә оегезгә кунсын...

**Наилә Насырова**